СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.12.2025 № 6/6

На № __________ от ______________

# КАРАР

## «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 28 августындагы 23/10 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Тукай муниципаль районының идарә структурасын камилләштерү, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты структурасын раслау турында» Тукай муниципаль районы Советының 2013 елның 28 августындагы 23/10 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә.

2. Вазифаны – 1 штат берәмлеген – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты урынбасары вазифасын чыгарырга.

3. Вазифаны – 1 штат берәмлеген – Башкарма комитетның эшләр идарәчесе вазифасын кертергә.

4. Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт вазифалары реестрына үзгәрешләр кертергә.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Тукай муниципаль районының сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

К.Р. Нәҗмиев